| МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.02.2021 Казан шәһ. № 238

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибен раслау хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законның 9 статьясындагы 5 өлеше нигезендә б о е р а м:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибен расларга.
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры урынбасары А.Д. Гариповка йөкләргә.

Министр М.Н.Садыйков

19.02.2021 № 238
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгы белән
расланды

## Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгындаТатарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибе

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибе (алга таба - Тәртип) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында (алга таба - Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен (алга таба - граждан хезмәткәрләре) коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү процедурасын регламентлый, яллаучы вәкиле Татарстан Сәламәтлек саклау министры (алга таба - министр) була.
2. Коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү, әлеге фактлар буенча тикшерү уздырылган яисә уздырыла торган очраклардан башка, граждан хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәттәге) бурычы була.
3. Коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары турында хәбәр итү (алга таба - Хәбәрнамә) граждан хезмәткәре тарафыннан язма рәвештә әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә төзелә.

Хәбәрнамәдә түбәндәге белешмәләр чагылдырлырга тиеш:

хәбәрнамә җибәрүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, биләүче вазыйфасы, яшәү урыны һәм телефоны;

дәүләт хезмәткәренә мөрәҗәгать итү факты булган очракта (очраклар мәгълүм булгач), аның хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында нинди дә булса затның мөрәҗәгать итүе тасвирламасы (датасы, урыны, вакыты, башка шартлар);

граждан хезмәткәренә кергән мөрәҗәгать итүнең коррупциячел хокук бозулар кылуга тартуны таныклаучы җентекле тасвирламасы (зат тарафыннан хезмәткәргә карата кылынган гамәлләр, тәкъдимнәр, белдерүләр, таләпләр, бүтән рәвештә мөрәҗәгать итүләр), шулай ук граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозуларга тарту билгеләре булган гамәлләр тасвирламасы;

коррупциячел хокук бозуларга тартучы физик (юридик) зат турында барлык мәгълүм белешмәләр;

коррупциячел хокук бозуларга тарту алымы һәм хәлләре (акча тәкъдим итү, янау, алдау, шантаж һәм башкалар), шулай ук затның коррупциячел хокук бозуларга

тарту тәкъдименнән баш тарту (килешү) турындагы мәгълүмат;

хәбәрнамәне прокуратура органнарына яисә башка дәүләт органнарына җибәрү турында мәгълүмат (нинди һәм кайчан).

Хәбәрнамәгә граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында нинди дә булса затларның мөрәҗәгать итүләре хәлләрен раслаучы барлык материаллар кушып бирелә.

4. Хәбәрнамә министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) исеменә языла һәм коррупциячел һәм бүтән төрле хокук бозуларны кисәтү эше өчен җаваплы затка (алга таба - Җаваплы зат) тапшырыла, әгәр әлеге тәкъдим хезмәттән тыш вакытта керсә, хезмәт итү урынына килүгә үк кичекмәстән тапшырыла.

Граждан хезмәткәре вазыйфаи (хезмәттәге) бурычларын үтәмәгән вакытта булганда яисә даими хезмәт урыннан читтә булганда, Хәбәрнамә почта юлламасы рәвешендә, факсимиль элемтә каналлары яисә электрон элемтәнең бүтән мөмкин булган каналлары аша җибәрелергә мөмкин, хезмәт урынына кайткannан соң Җаваплы затка Хәбәрнамәнең төп нөсхәсе тапшырыла.

5. Җаваплы зат Хәбәрнамәне Граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы вәкиленә хәбәр итүләрне теркәү журналында (алга таба - Журнал) әлеге Тәртипкә кушымта №2 нигезендәге форма буенча терки.

Хәбәрнамәне кабул итеп алган зат турындагы белешмәләрне һәм аны теркәү датасын күрсәтеп, дәүләт хезмәткәренә, имза салдырып, Хәбәрнамә күчермәсе тапшырыла.

6. Алынган белешмәләрнең конфиденциальлеге «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге № 152-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә тәэмин ителә.

7. Җаваплы зат Хәбәрнамәне теркәгән көнне үк аны эчке эшләр органнарына яисә башка дәүләт органнарына җибәрү турында карар кабул итү өчен министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) җибәрелә.

8. Министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) Хәбәрнамәне эчке эшләр органнарына яисә башка дәүләт органнарына җибәрү турында карар кабул иткән очракта, Җаваплы зат, мондый карар кабул ителгән көннән ике эш көненнән дә соңга калмыйча, Хәбәрнамәне, материалларын кушып, тиешле органнарга җибәрә.

9. Коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары хакында яллаучы вәкиленә, прокуратура органнарына яисә башка дәүләт органнарына хәбәр иткән дәүләт хезмәткәре Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт яклавында була.

10. Дәүләт хезмәткәренең коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү фактлары хакында яллаучы вәкиленә хәбәр итү вазыйфаларын үтәмәве аны «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законның 9 статьясы нигезендә дәүләт хезмәтеннән җибәрүгә йә Россия Федерациясе законнары нигезендә бүтән төр җаваплылыкка тартуга китерә торган хокук бозу була.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибенә
Кушымта № 1

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрына
____________________________________________
(фамилия, инициаллар)

____________________________________________
((кемнән)фамилия, исеме, атасы исеме, дәүләт хезмәткәренең биләүче вазыйфасы)

Дәүләт хезмәткәренең яшәү урыны
адресы:________________________________________
____________________________________________
Дәүләт хезмәткәренең телефон номеры_______________

Коррупциячел хокук бозулар кылуга өндәү максатларында мөрәҗәгать итү фактлары хакында хакында яллаучы вәкиленә
ХӘБӘРНАМӘ

Түбәндәге зат тарафыннан мине коррупциячел хокук бозу кылуга тарту максатларында мөрәҗәгать итү факты хакында хәбәр итәм____________________________
____________________________________________________________________
(хокук бозуга тартучы фамилия-исем, вазыйфасы, физик(юридик) зат турында барлык мәгълүм белешмәләр)

Хокук бозуга тарту мине түбәндәгеләрне башкару максатларда гамәлгә ашырылды
____________________________________________________________________
(коррупциячел хокук бозу билгеләре булган гамәлләр тасвирламасы күрсәтелә)

Хокук бозуга тарту түбәндәге юл белән гамәлгә ашырылды________________________
____________________________________________________________________
(коррупциячел хокук бозуларга тарту алымы (акча тәкъдим итү, янау, алдау һәм башкалар)

Хокук бозуга тарту ________сәгатьтә _____ минутта «_____» ________ 20___ елда ___________________________________________________ адресы буенча башкарылды.

Хокук бозуга тарту түбәндәгечә гамәлгә ашырылды ______________________________
____________________________________________________________________
(телефоннан сөйләшкәндә, шәхси очрашу барышында, почта аша һәм башкача)

Коррупциячел хокук бозу турында тәкъдим кабул итүдән баш тарту яки ризалык турында белешмәләр___________________________________________________________

Прокуратура органнарына йә башка дәүләт органнарына хәбәр итү турында белешмәләр_______________________________________________________________

(нинди дәүләт органнарына хәбәр ителгән, хәбәр итү датасы)

Кушымта: ____________________________________________________________

(кушымта итеп бирелгән материаллар исемлеге)

Тутыру датасы: _______________ Дәүләт хезмәткәре имзасы: _____________________

Теркәлгән «______» ______________ 20___ елда Теркәлү №___________________________

Татарстан Республикасы Сәламәтлек
саклау министрлыгында коррупциячел
һәм бүтән төрле хокук бозуларны кисәтү
эше өчен җаваплы зат ____________________/_______________________

имза расшифровка

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы (эш бирүче) вәкиленә хәбәр итү тәртибенә
Кушымта № 2

Дәүләт хезмәткәрен коррупциячел хокук бозулар кылуга тарту максатларында аңа мөрәҗәгать итү фактлары турында яллаучы вәкиленә хәбәр итүләрне теркәү ЖУРНАЛЫ

| № т/н | Хәбәрнамәне теркәү датасы | Хәбәрнамәне тапшырган затның исем-фамилиясе, дәүләт хезмәткәре имзасы | Хәбәрнамәне тапшыру ысылу | Хәбәрнамәнең кыскача эчтәлеге | Регистраторның исем-фамилиясе, имзасы | Искәрмәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |